ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 11 2025 г. № 271

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә чиннар бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Кодексының муниципаль хезмәт турындагы 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләренә туры килүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Башлыгы карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Башлыгының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең чиннары хакында» 2016 елның 29 февралендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә чиннар бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.2. 22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Муниципаль хезмәткәргә чин бирү турындагы карар (әлеге Нигезләмәнең 16 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш), органга яисә җирле үзидарәнең чиннар бирергә вәкаләтле вазыйфаи затына, чин бирү турында барлык кирәкле документлар белән бергә күрсәтмә кертелгән көннән алып, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш:».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль район Башлыгы Р. Р. Нотфуллин